**Аллаһы Тәгалә каршында дәлил**

# Намаз - Аллаһы Тәгалә белән очрашу

Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгалә Коръәни-Кәримендә әйтәдер:

«Миңа гына гыйбадәт кыл

вә Мине генә зикер итәр өчен намаз укы!»

Намаз укыган кешенең кальбе нурлана,

ул авырулардан пакьләнә.

Эчке дөньясын яктыртырга,

караңгылыктан чыгарга теләүчеләр,

әлбәттә, намаз укырга тиешләр.

Пәйгамбәребезгә һәм аның өммәтенә намаз уку мигъраҗ вакытында,

ягъни Пәйгамбәребез Аллаһы белән очрашканда фарыз ителде.

Биш вакыт намазны вакытында укып, калган фарызларны да үтәп, хәрамнәрдән сакланып яшәгән кеше мөэмин-мөселман була.

Аллаһы Тәгалә биш вакыт намаз укучы, ураза тотучы, зәкят-садака бирүче мөэмин-мөселманнарны гына Үзенең рәхмәте белән җәннәткә кертәчәк.

Пәйгамбәребез (с.г.с.) үзенең хәдисләрендә намаз укуның әҗер-саваплары турында әйтеп калдырган:

**«Берәү биш вакыт намазны җәмәгать белән укыса, аңа биш нәрсә бүләк ителер**:

1) дөньяда аңа бичаралык ирешмәс;

2) ул кешедән Аллаһы Тәгалә гүр газабын күтәрер;

3) гамәл дәфтәре уң кулына бирелер;

4) сират күпереннән яшен тизлеге белән үтәр;

5) биш вакыт намазны җәмәгать белән укыганнарны җәннәткә хисапсыз вә газапсыз кертерләр».

«Намаз-Аллаһы Тәгаләнең ризалыгыдыр вә Пәйгамбәрләрнең сөннәтедер.

**Намаз - фәрештәләрнең яраткан гыйбадәтедер.**

Намаз - мәгърифәт нурыдыр вә иманның асылыдыр.

**Намаз - дошманның күзенә каршы коралдыр.**

Намаз - шайтанның яратмаган нәрсәседер.

Намаз үз иясен Кыяметтә шәфәгать кылыр.

Намаз Газраил галәйһиссәлам җан алырга килгәндә шәфкать кылыр, ул кеше җиңеллек белән җан бирер.

**Намаз кыямәт көненә кадәр иясенең каберен яктыртып торыр.**

Намаз кыямәт көнендә баш өстенә күләгә булыр.

Намаз тәнгә кием булыр.

**Намаз тәмуг утыннан пәрдә булыр.**

Намаз Аллаһы Тәгалә каршында дәлил булыр».

* * *

**Белмәсәгез, белегез**

## Индеецлар телендә «Аллаһы» сүзе бар

Индеецларның мөселман булуларына караган барлык документлар АКШ Конгрессы китапханәсендә һәм архивларда саклана.

Маһир Габдерразак үзе дә индеецлар тарихы буенча фәнни тикшеренүләр алып бара. Шул эш нәтиҗәләренә караганда, индеец кабиләләре телендә гарәп, фарсы, төрки һәм гыйбрани (иврит) телләренең тәэсире сизелә. Бөтен кабилә телләрендә диярлек «Аллаһы» сүзе бар.

Тагын бер кызыклы әйбер: индеец хатын-кызлары, гадәттә, башларына яулык бөркәнә, ир-атларның да киемнәре тез капкачларын капларлык озынлыкта була. Бу мөселманча киенү шартларына туры килә.

## Колумб мөселманнар белән очрашкан

Маһир Габдерразак юлламасында: Христофор Колумб Америкага тәүге килгәндә мөселман индеецлар белән очрашкан, диелә.

Моннан тыш, 1654 елда Американың ерак төбәкләрендә инглизләрнең сакаллы һәм мөселманнар шикелле гыйбадәт кылучы индеецларны күргәннәре мәгълүм.

1690 нчы елларда французларның Төньяк Америка кыйтгасында *«Мәлүнҗан»* исемле мөселман кавеме белән элемтәгә керүләре дә тарихи документларда теркәлгән.

* * *

**Дөнья күргәннәргә таян**

## Әс-сәлләм

Бу шәрәфле исем Аллаһы Тәгаләнең аз гына булса да кимчелеге, гаебе юклыкны, афәткә, бәла-казага юлыкмаячагын аңлата.

Мондый мәгънәсе аның *әл-Коддус* дигән гүзәл исеменә якынлыкка ишарә итсә дә, соңгысының киләчәккә юнәлдерелгәнлеге тагын да көчлерәк сизелә.

Ягъни Аллаһы Тәгаләнең шәхесе булсын, берәр сыйфаты булсын — ул киләчәктә бернинди үзгәреш тә кичермәячәк.

Ул һичнинди кысалар белән чикләнмәгән һәм һәрвакыт даими.

Ул беркайчан да юк булмаячак.

Аның гыйлеме зәгыйфьләнмәячәк, көч-кодрәте кимемәячәк, мөлкәте кулыннан ычкынмаячак.

Бу сыйфат бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә хас.

Аннан башка бөтен һәм исән-сау кала торган һичбер нәрсә юк.

Бар әйбер юк ителәчәк,

солтан — кол,

белемле — надан,

көчле — зәгыйфь калачак.

Берәүгә дә ышанып, тормыштагы бер нәрсәгә дә инанып булмый — бер мизгелдә бары да ялганга әверелергә мөмкин.

*«Агачка таянма — корыр, кешегә ышанма — үләр»,* ди дөнья күргән картлар.

Һәр эштә бу дөньяга килеп китүчеләргә түгел, фәкать Аллаһы Тәгаләгә генә таянырга, Аннан гына берәр нәрсә өмет итәргә мөмкин.

Чөнки бары Ул гына, егылмыйча, төрле бәла-казадан исән-сау калачак.

**Әс-Сәлләм** гүзәл исемен бу дөньяда да, ахирәттә дә үзенең колларын куркыныч хәлләрдән коткарып калучы дип тә аңлатырга мөмкин булыр иде.

Билгеле,

Үзе теләгән вакытта

һәм Үзе теләгән колын гына.

Һәртөрле саулык аның кодрәтендә булган кебек, теләгәнен сәламәтләндерү дә Аның кодрәтендә.

Сәламәтлекне Аннан гына алырга мөмкин һәм рәхмәтебезне дә Аңа җиткерергә тиешбез.

* * *

**Намаз вакытлары** — Хиҗри буенча 1434 ел — **Май ае тәкъвиме** — Милади буенча 2013 ел — **Время намазов**

| Көннәр саны | | Хиҗри буенча | | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Зәвәл | Өйлә | Икенде | Ахшам | Көн озынлыгы | Ястү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | чәршәмбе | 20 | Җөмәдел | 3:36 | 5:06 | 12:37 | 13:05 | 17:45 | 20:11 | *15:05* | 21:41 |
| 2 | пәнҗешәмбе | 21 | әл-әүвәл | 3:34 | 5:04 | 12:37 | 13:05 | 17:46 | 20:13 | *15:09* | 21:43 |
| 3 | җомга | 22 | | 3:32 | 5:02 | 12:37 | 13:05 | 17:48 | 20:14 | *15:12* | 21:44 |
| 4 | шимбә | 23 | | 3:30 | 5:00 | 12:37 | 13:05 | 17:49 | 20:16 | *15:16* | 21:46 |
| 5 | якшәмбе | 24 | | 3:28 | 4:58 | 12:36 | 13:05 | 17:50 | 20:18 | *15:20* | 21:48 |
| 6 | дүшәмбе | 25 | | 3:26 | 4:56 | 12:36 | 13:05 | 17:61 | 20:20 | *15:24* | 21:50 |
| 7 | сишәмбе | 26 | | 3:24 | 4:54 | 12:36 | 13:05 | 17:52 | 20:21 | *15:27* | 21:51 |
| 8 | чәршәмбе | 27 | | 3:23 | 4:53 | 12:36 | 13:05 | 17:53 | 20:23 | *15:30* | 21:53 |
| 9 | пәнҗешәмбе | 28 | | 3:21 | 4:51 | 12:36 | 13:05 | 17:54 | 20:25 | *15:34* | 21:55 |
| 10 | җомга | 29 | | 3:19 | 4:49 | 12:36 | 13:05 | 17:55 | 20:26 | *15:37* | 21:56 |
| 11 | шимбә | Җөмәдел | 1 | 3:17 | 4:47 | 12:36 | 13:05 | 17:56 | 20:28 | *15:41* | 21:58 |
| 12 | якшәмбе | әл-ахир | 2 | 3:15 | 4:45 | 12:36 | 13:05 | 17:57 | 20:30 | *15:45* | 22:00 |
| 13 | дүшәмбе | | 3 | 3:14 | 4:44 | 12:36 | 13:05 | 17:58 | 20:31 | *15:47* | 22:01 |
| 14 | сишәмбе | | 4 | 3:12 | 4:42 | 12:36 | 13:05 | 17:59 | 20:33 | *15:51* | 22:03 |
| 15 | чәршәмбе | | 5 | 3:10 | 4:40 | 12:36 | 13:05 | 18:00 | 20:35 | *15:55* | 22:05 |
| 16 | пәнҗешәмбе | | 6 | 3:09 | 4:39 | 12:36 | 13:05 | 18:01 | 20:36 | *15:57* | 22:06 |
| 17 | җомга | | 7 | 3:07 | 4:37 | 12:36 | 13:05 | 18:02 | 20:38 | *16:01* | 22:08 |
| 18 | шимбә | | 8 | 3:06 | 4:36 | 12:36 | 13:05 | 18:02 | 20:40 | *16:04* | 22:10 |
| 19 | якшәмбе | | 9 | 3:04 | 4:34 | 12:36 | 13:05 | 18:03 | 20:41 | *16:07* | 22:11 |
| 20 | дүшәмбе | | 10 | 3:03 | 4:33 | 12:36 | 13:05 | 18:04 | 20:43 | *16:10* | 22:13 |
| 21 | сишәмбе | | 11 | 3:01 | 4:31 | 12:36 | 13:05 | 18:05 | 20:44 | *16:13* | 22:14 |
| 22 | чәршәмбе | | 12 | 3:00 | 4:30 | 12:36 | 13:05 | 18:06 | 20:46 | *16:16* | 22:16 |
| 23 | пәнҗешәмбе | | 13 | 2:59 | 4:29 | 12:37 | 13:05 | 18:07 | 20:47 | *16:18* | 22:17 |
| 24 | җомга | | 14 | 2:57 | 4:27 | 12:37 | 13:05 | 18:08 | 20:49 | *16:22* | 22:19 |
| 25 | шимбә | | 15 | 2:56 | 4:26 | 12:37 | 13:05 | 18:08 | 20:50 | *16:24* | 22:20 |
| 26 | якшәмбе | | 16 | 2:55 | 4:25 | 12:37 | 13:05 | 18:09 | 20:51 | *16:26* | 22:21 |
| 27 | дүшәмбе | | 17 | 2:54 | 4:24 | 12:37 | 13:05 | 18:10 | 20:53 | *16:29* | 22:23 |
| 28 | сишәмбе | | 18 | 2:52 | 4:22 | 12:37 | 13:05 | 18:11 | 20:54 | *16:32* | 22:24 |
| 29 | чәршәмбе | | 19 | 2:51 | 4:21 | 12:37 | 13:05 | 18:12 | 20:55 | *16:34* | 22:25 |
| 30 | пәнҗешәмбе | | 20 | 2:50 | 4:20 | 12:37 | 13:05 | 18:12 | 20:57 | *16:37* | 22:27 |
| 31 | җомга | | 21 | 2:49 | 4:19 | 12:37 | 13:05 | 18:13 | 20:58 | *16:39* | 22:28 |
| Дни | | Хиджри | | Фаджр | Восход | Зенит | Зухр | Аср | Магриб | Долгота дня | Иша |

Ковры на любой вкус



Представитель Кайракумского коврового комбината Республики Таджикистан в РФ предлагает высококачественные изделия в широком ассортименте:

- шерстяные,
- полушерстяные,
- искусственные,
- молитвенные ковры разных размеров от 1 кв. м. до 1000 кв. м,
- одинарные коврики - намазлык (молитвенники) разных размеров и колоритов, а также гаммы.

**Обращаться по адресу:**
**г. Самара, ул. Стара-Загора, 54, к Абдурахману Батуру.**
**Контактные телефоны:**
**(8-8460)225-04-30,**
**8-927-010-05-05,**
**8-917-817-00-04.**